МИНИСТЕРСТВО ТРАНСПОРТА
И ДОРОЖНОГО ХОЗЯЙСТВА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТРАНСПОРТ ҺӘМ ЮЛ
ХУҖАЛЫГЫ МИНИСТРЛЫГЫ

**БОЕРЫК** **ПРИКАЗ**

от “16” 06. 2026 № 63

Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгында вазыйфа биләү коррупция куркынычларына бәйле булган, вазыйфа биләгәндә дәүләт граждан хезмәткәрләре үзләренең керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәт рәвешендәге йөкләмәләре турында белешмәләр, шулай ук үзләренең хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәт рәвешендәге йөкләмәләре турында белешмәләр тапшырырга тиешле булган Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары исемлеген раслау турында

«Коррупциягә каршы көрәш турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы федераль законның 8 статьясы, Татарстан Республикасы Президентының «Вазыйфа биләгәндә Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре үзләренең керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәт рәвешендәге йөкләмәләре турында белешмәләр, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәт рәвешендәге йөкләмәләре турында белешмәләр тапшырырга тиешле булган Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары исемлеген раслау турында» 2009 елның 30 декабрендәге ПУ-701 номерлы, «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларын биләүне дәгъвалаучы гражданнар һәм Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре тарафыннан керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәт рәвешендәге йөкләмәләре турында белешмәләр бирү хакында» 2009 елның 30 декабрендәге ПУ-702 номерлы указлары нигезендә боерык бирәм:

1. Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгында вазыйфа биләү коррупция куркынычларына бәйле булган, вазыйфа биләгәндә дәүләт граждан хезмәткәрләре үзләренең керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәт рәвешендәге йөкләмәләре турында

белешмәләр, шулай ук үзләренең хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәт рәвешендәге йөкләмәләре турында белешмәләр тапшырырга тиешле булган Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары исемлеген (алга таба – исемлек) (кушымтада бирелә) расларга.

2. Дәүләт хезмәте һәм кадрлар бүлегенә Исемлеккә кертелгән вазыйфаларны биләгән дәүләт граждан хезмәткәрләренә эштән киткәндә «Коррупциягә каршы көрәш турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы федераль законның 12 статьясында каралган чикләмәләре, бурычлары һәм җаваплылыклары турында аңлатырга.

3. Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгының «Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгында вазыйфа биләү коррупция куркынычына бәйле булган, вазыйфа биләгәндә Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре үзләренең керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәт рәвешендәге йөкләмәләре турында белешмәләр, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәт рәвешендәге йөкләмәләре турында белешмәләр тапшырырга тиешле булган Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары исемлеген раслау турында» 2024 елның 11 декабрендәге 98 номерлы боерыгын гамәлдән чыккан дип танырга.

4. Бу боерык үтәлешен контрольдә тоту буенча үземне җаваплы итеп билгелим.

Министр Ф.М. Хәнифов

Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгының 2026 елның 16 июнендәге 63 номерлы боерыгы белән расланды

Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгында вазыйфа биләү коррупция куркынычларына бәйле булган, вазыйфа биләгәндә дәүләт граждан хезмәткәрләре үзләренең керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәт рәвешендәге йөкләмәләре турында белешмәләр, шулай ук үзләренең хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәт рәвешендәге йөкләмәләре турында белешмәләр тапшырырга тиешле булган Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары исемлеге

1. Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең иң югары вазыйфалар төркемендәге «җитәкчеләр» категориясе вазыйфалары:

министрның беренче урынбасары;

министр урынбасары.

2. Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең әйдәп баручы вазыйфалар төркемендәге «ярдәмчеләр (киңәшчеләр)» категориясе вазыйфалары:

министр ярдәмчесе.

3. Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең төп вазыйфалар төркемендәге «җитәкчеләр» категориясе вазыйфалары:

эшләр идарәчесе;

Стратегик үсеш идарәсе башлыгы;

Транспорт идарәсе җитәкчесе;

Автомобиль юллары идарәсе башлыгы;

финанс бүлеге башлыгы;

юридик бүлек җитәкчесе;

дәүләт хезмәте һәм кадрлар бүлеге җитәкчесе;

режим, мобилизацияле әзерлек, гражданнар оборонасы һәм гадәттән тыш хәлләр бүлеге җитәкчесе;

инфраструктура менюсы һәм дәүләт-хосусый партнерлык проектларын гамәлгә ашыру бүлеге җитәкчесе;

административ хокук бозуларны контрольдә тоту бүлеге җитәкчесе.

4. Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең әйдәп баручы вазыйфалар төркемендәге «җитәкчеләр» категориясе вазыйфалары:

Автомобиль юллары идарәсенең юл хәрәкәте иминлеге һәм контроль-күзәтчелек эшчәнлеге секторы мөдире;

транспорт объектларын террорчылыктан саклау секторы мөдире;

хезмәтне саклау һәм экологик куркынычсызлык секторы мөдире;

дәүләт сатып алулары секторы мөдире;

системалы администрацияләү һәм цифрлаштыру секторы мөдире.

5. Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең әйдәп баручы вазыйфалар төркемендәге «белгечләр» категориясе вазыйфалары:

Стратегик үсеш идарәсенең бюджетны планлаштыру бүлеге җитәкчесе;

Стратегик үсеш идарәсенең тармак аудиты һәм предприятиеләр эшчәнлеген анализлау бүлеге җитәкчесе;

Транспорт идарәсенең автомобиль транспорты бүлеге җитәкчесе;

Транспорт идарәсенең тимер юл транспорты бүлеге җитәкчесе;

Транспорт идарәсенең һава һәм су транспорты бүлеге җитәкчесе;

Автомобиль юллары идарәсенең автомобиль юллары бүлеге җитәкчесе;

Автомобиль юллары идарәсенең транспорт инфраструктурасын үстерү һәм федераль программалар бүлеге җитәкчесе;

оештыру үсеше бүлеге җитәкчесе;

оештыру эшләре бүлеге җитәкчесе урынбасары;

юридик бүлекнең әйдәп баручы киңәшчесе;

дәүләт хезмәте һәм кадрлар бүлегенең әйдәп баручы киңәшчесе;

Транспорт идарәсенең автомобиль транспорты бүлегенең әйдәп баручы киңәшчесе;

Транспорт идарәсенең тимер юл транспорты бүлегенең әйдәп баручы киңәшчесе;

Транспорт идарәсенең һава һәм су транспорты бүлегенең әйдәп баручы киңәшчесе;

Стратегик үсеш идарәсенең бюджетны планлаштыру бүлегенең әйдәп баручы киңәшчесе;

Стратегик үсеш идарәсенең тармак аудиты һәм тармак предприятиеләре эшчәнлеген анализлау бүлегенең әйдәп баручы киңәшчесе;

Автомобиль юллары идарәсенең автомобиль юллары бүлегенең әйдәп баручы киңәшчесе;

Автомобиль юллары идарәсенең транспорт инфраструктурасын үстерү һәм федераль программалар бүлегенең әйдәп баручы киңәшчесе;

инфраструктура менюсы һәм дәүләт-хосусый партнерлык проектларын гамәлгә ашыру бүлегенең әйдәп баручы киңәшчесе;

административ хокук бозуларны контрольдә тоту бүлегенең әйдәп баручы киңәшчесе;

дәүләт хезмәте һәм кадрлар бүлегенең әйдәп баручы консультанты;

Транспорт идарәсенең автомобиль транспорты бүлегенең әйдәп баручы консультанты;

Транспорт идарәсенең һава һәм су транспорты бүлегенең әйдәп баручы консультанты;

Стратегик үсеш идарәсенең бюджетны планлаштыру бүлегенең әйдәп баручы консультанты;

Стратегик үсеш идарәсенең тармак аудиты һәм тармак предприятиеләре эшчәнлеген анализлау бүлегенең әйдәп баручы консультанты;

Автомобиль юллары идарәсенең автомобиль юллары бүлегенең әйдәп баручы консультанты;

Автомобиль юллары идарәсенең транспорт инфраструктурасын үстерү һәм федераль программалар бүлегенең әйдәп баручы консультанты;

инфраструктура менюсы һәм дәүләт-хосусый партнерлык проектларын гамәлгә ашыру бүлегенең әйдәп баручы консультанты;

административ хокук бозуларны контрольдә тоту бүлегенең әйдәп баручы консультанты;

Автомобиль юллары идарәсенең юл хәрәкәте иминлеге һәм контроль-күзәтчелек эшчәнлеге секторының әйдәп баручы консультанты;

транспорт объектларының террорчылыктан саклану секторының әйдәп баручы консультанты.

6. Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең әйдәп баручы вазыйфалар төркемендәге «тәэмин итүче белгечләр» категориясе вазыйфалары:

финанс бүлегенең әйдәп баручы белгече;

юридик бүлекнең әйдәп баручы белгече;

дәүләт хезмәте һәм кадрлар бүлегенең әйдәп баручы белгече;

режим, мобилизацияле әзерлек, гражданнар оборонасы һәм гадәттән тыш хәлләр бүлегенең әйдәп баручы белгече;

Транспорт идарәсенең тимер юл транспорты бүлегенең әйдәп баручы белгече;

инфраструктура менюсы һәм дәүләт-хосусый партнерлык проектларын гамәлгә ашыру бүлегенең әйдәп баручы белгече;

административ хокук бозуларны контрольдә тоту бүлегенең әйдәп баручы белгече;

дәүләт сатып алулары секторының әйдәп баручы белгече.

7. Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең өлкән вазыйфалар төркемендәге «тәэмин итүче белгечләр» категориясе вазыйфалары:

Транспорт идарәсенең автомобиль транспорты бүлегенең 1 разрядлы өлкән белгече;

Стратегик үсеш идарәсенең тармак аудиты һәм тармак предприятиеләре эшчәнлеген анализлау бүлегенең 1 разрядлы өлкән белгече;

Автомобиль юллары идарәсенең автомобиль юллары бүлегенең 1 разрядлы өлкән белгече;

хезмәтне саклау һәм экологик иминлек секторының 1 разрядлы өлкән белгече.